**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 апрель № 210

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 июнь, 430 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 1 086,4 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты чаралары– 688,4 млн. сум:<br>2014 ел – 20,0 млн.сум;<br>2015 ел – 97,3 млн.сум;<br>2016 ел – 44,9 млн.сум;<br>2017 ел – 26,4 млн.сум;<br>2018 ел – 163,0 млн.сум; |

| | |
|---|---|
| | 2019 ел – 169,0 млн.сум;<br>2020 ел – 167,8 млн.сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырылган муниципаль бюджет чаралары – 5,1 млн.сум:<br>2014 ел – 3,3 млн.сум;<br>2015 ел – 1,8 млн.сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырылган бюджеттан тыш чаралар – 392,9 млн.сум:<br>2014 ел – 0 млн.сум;<br>2015 ел – 0 млн.сум;<br>2016 ел – 8,0 млн.сум;<br>2017 ел – 11,0 млн.сум;<br>2018 ел – 118,9 млн.сум;<br>2019 ел – 124,7 млн.сум;<br>2020 ел – 130,3 млн.сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле елга һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Программада Татарстан Республикасы территориясендә туристларга ял итү һәм автотуристик кластерлар төзү күздә тотыла.<br>Әлеге чаралар төзелә торган кластерларны «Россия Федерациясендә эчке һәм читтән керүче туризмны үстерү (2011 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасына керткән очракта гамәлгә ашырылачак.<br>Программаның әлеге чараларын финанслау күләмнәре кластерларның проект документларын, Татарстан Республикасы бюджеты чаралары капиталь кертемнәре планын рәсмиләштергәндә тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганакларның күздә тотылган акчасы ел саен төзелә торган килешүләр һәм шартнамәләр нигезендә билгеләнәчәк.»; |

Программаның I бүлегенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә эчке һәм читтән керә торган туристлыкны үстерү (2011 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасы турында» 2011 ел, 2 август, 644 нче карары белән расланган «Россия Федерациясендә эчке һәм читтән керә торган туристлыкны үстерү (2011 – 2018 еллар)» федераль максатчан программасының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 ел, 7 февраль, 165-б боерыгы белән расланган 2020 елга кадәр чорда Идел буе федераль округын социаль-икътисади үстерү стратегиясенең төп нигезләмәләре нигезендә эшләнгән һәм «2009 – 2011 елларга Татарстан Республикасында туристлык тармагын үстерү» республика максатчан программасының дәвамы булып тора.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 1 086,4 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты чаралары – 688,4 млн.сум:
2014 ел – 20,0 млн.сум;
2015 ел – 97,3 млн.сум;
2016 ел – 44,9 млн.сум;
2017 ел – 26,4 млн.сум;
2018 ел – 163,0 млн.сум;
2019 ел – 169,0 млн.сум;
2020 ел – 167,8 млн.сум;

билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырылган муниципаль бюджет чаралары — 5,1 млн.сум:
2014 ел – 3,3 млн.сум;
2015 ел – 1,8 млн.сум;

билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырылган бюджеттан тыш чаралар – 392,9 млн.сум:
2014 ел – 0 млн.сум;
2015 ел – 0 млн.сум;
2016 ел – 8,0 млн.сум;
2017 ел – 11,0 млн.сум;
2018 ел – 118,9 млн.сум;
2019 ел – 124,7 млн.сум;
2020 ел – 130,3 млн.сум.»;

Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков